КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 20 март г.Казань № 165

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында

Татарстан Республикасының Аксубай муниципаль районында «Аксубай – Емелькино – Яңа Чуаш Әдәмсуы» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының VII бүлегендәге 49 статьясы, VII[1] бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Татарстанның юл-транспорт идарәсе) Татарстан Республикасының Аксубай муниципаль районында «Аксубай – Емелькино – Яңа Чуаш Әдәмсуы» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен Татарстан Республикасы, Аксубай муниципаль районы адресы буенча урнашкан, дәүләт милкендә булган һәм «Волга-Селект» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә (алга таба – алына торган җир кишәрлеген арендага алучы) тапшырылган, 2 168 000,24 кв.метр мәйданлы һәм 16:03:000000:564 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән барлыкка килә торган 2 903 кв.метр мәйданлы җир кишәрлеген (алга таба – алына торган җир кишәрлеге) алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. 16:03:000000:564 кадастр номерлы җир кишәрлегендә урнашкан 16:03:000000:1814 кадастр номерлы «Торак булмаган. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Иске Чуаш Әдәмсуы авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен реконструкцияләү», 16:03:000000:1854 кадастр номерлы «Юл

транспорты корылмалары. «Аксубай – Емелькино – Иске Татар Әдәмсуы» автомобиль юлы», 16:03:000000:2310 кадастр номерлы «Торбаүткәргеч транспорт корылмалары. Югары басымлы газүткәргеч» капиталь төзелеш объектлары алынмаска тиеш, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен алына торган җир кишәрлеген арендага алучыга, «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен түләү күләме билгеләнгәннән соң 30 көн эчендә алына торган җир кишәрлегенә аренда шартнамәсе туктатылу турында килешү (алга таба – килешү) әзерләүне һәм аны алына торган җир кишәрлеген арендага алучыга җибәрүне;

килешү төзүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен акча түләүне;

алына торган җир кишәрлеген арендага алучы тарафыннан кул куелган килешү законнар белән билгеләнгән срокта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъва бирүне.

4. Татарстанның юл-транспорт идарәсенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында «Аксубай – Емелькино – Яңа Чуаш Әдәмсуы» автомобиль юлын реконструкцияләү» объектын урнаштыру өчен территорияне планлаштыру проектын һәм межалау проектын раслау турында» 2023 ел, 2 июнь, 148 нче карары белән расланган территорияне планлаштыру проекты һәм межалау проекты нигезендә 16:03:000000:564 кадастр номерлы җир кишәрлегенә һәм алына торган җир кишәрлегенә карата кадастр эшләрен башкаруны;

алына торган җир кишәрлеге өчен акча түләү күләмен билгеләүне.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин